# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 11*
*ноябрь*
*(I өлеш)*
*2013*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
2013

ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84 1/16. Тираж 65 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2013

Эчтәлек

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

1254. «Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................5
1255. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................6
1256. «Җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турындагы Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................8
1257. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .....9
1258. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................11
1259. «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................14
1260. «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................16
1261. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге турында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................17

1262. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................22
1263. «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................30

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1254. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш); 2007, № 10; 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) ике гражданлыкка ия затлар.»;

2) 15 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $11^2$ пункт өстәргә:

«$11^2$) федераль законнар нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы составына үз составыннан вәкил сайлау тәртибе;»;

3) $16^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Иҗтимагый палата рәисе Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы составына сайланган очракта, ул Иҗтимагый палата рәисе вәкаләтләрен үз өстеннән төшерергә тиеш.»;

4) 20 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Иҗтимагый палатаның, Иҗтимагый палата Советының, Иҗтимагый палатаның структур бүлекчәләренең бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгатьләр рәвешендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү төсмеренә ия.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 6 ноябре
№ 85-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1255. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның дүртенче абзацында «дәүләт идарәсе» сүзләрен «башкарма хакимияте» сүзләренә алмаштырырга;

2) $1^1$ статьяда:

а) беренче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) икенче өлештә «районнарның, шәһәрләрнең администрацияләре» сүзләрен «җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяда:

а) беренче өлештә «район, шәһәр яисә шәһәрдәге район җирле администрациясенә» сүзләрен «җирле үзидарә органына» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) өченче өлештә «район, шәһәр яисә шәһәрдәге район җирле администрациясе» сүзләрен «җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяның беренче өлешендә «Республика» сүзен төшереп калдырырга, «халык депутатларының җирле Советлары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5) 11 статьяның икенче өлешендә «район, шәһәр һәм шәһәрдәге район җирле администрациясенең» сүзләрен «җирле үзидарә органының» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 6 ноябре
№ 86-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1256. Җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турындагы Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

1) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 17 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I часть); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш);

2) «Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш);

3) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 10 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш).

**2 статья**

Әлеге Закон 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 6 ноябре
№ 87-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1257. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 4 пунктта «ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар,» сүзләреннән соң «ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ һәм $4^2$ пунктлар өстәргә:

«$4^1$) ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы гаиләгә урнаштыруга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затлар;

$4^2$) уллыкка алынган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, уллыкка алучылар;»;

2) 2 өлештә:

а) 2 пунтка «социаль наем шартнамәсе» сүзләреннән соң «, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсус торак урыннарын яллау шартнамәсе,» сүзләрен, «булган очракта)» сүзләреннән соң «, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсен өзү һәм туктату, күрсәтелгән торак урыннарыннан чыгарылу» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ һәм $10^2$ пунктлар өстәргә:

«$10^1$) уллыкка алуны, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека һәм попечительлек билгеләү, мондый балаларга опеканы һәм попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү;

$10^2$) ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;»;

3) 3 өлештә:

а) 1 пунктның «б» пунктчасына «социаль наем шартнамәсе» сүзләреннән соң «, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, шул исәптән гаиләгә тәрбиягә алынган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсе» сүзләрен, «булган очракта)» сүзләреннән соң «, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсен өзү һәм туктату, күрсәтелгән торак урыннарыннан чыгарылу» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) судларда түбәндәгеләр турында эшләр каралганда дәгъвачылар (мөрәҗәгать итүчеләр) булсалар:

а) алиментлар түләттерү;

б) туендыручысының хезмәт эшчәнлегенә бәйле рәвештә вафат булуы, имгәнүе яисә сәламәтлегенә башкача зарар килү аркасында китерелгән зыянны түләттерү;

в) уллыкка алуны, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека һәм попечительлек билгеләү, мондый балаларга опеканы һәм попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү;

г) инвалид балаларга, ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга дәүләт ярдәме чараларын тәэмин итү;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 ноябре
№ 88-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1258. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^1$ статьясындагы $3^1$ пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7; Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «билгеләнә» сүзен «раслана» сүзенә алмаштырырга;

2) 6 пунктчада «һәм чыгымнар төрләре» сүзләрен «һәм чыгымнар төрләре төркемнәре» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 3 өлештә «субвенцияләрнең күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «субвенцияләрнең күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

2) 1 нче кушымтада:

а) исемдә «субвенцияләрнең күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «субвенцияләрнең күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта татарча текст үзгәрми;

дүртенче абзацта татарча текст үзгәрми;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$S_{ti1}$ – эпидемиягә каршы чаралар үткәрүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган бәясе.»;

3) 2 нче кушымтада:

а) исемдә «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта татарча текст үзгәрми;
дүртенче абзацта татарча текст үзгәрми.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 пунктында «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

2) кушымтада:
а) исемдә «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;
б) 1 пунктта «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;
в) 2 пунктта:
беренче абзацта татарча текст үзгәрми;
бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Р – саклау берәмлеген карап тотуга чыгымнарның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нормативы;».

**4 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^1$ статьясы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә), 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 ноябре
№ 89-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1259. «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 11 статьяның 3 пунктында «яисә» сүзеннән соң «Татарстан Республикасының» сүзләрен өстәргә;

3) 12 статьяда:

а) 1 өлешнең 6 һәм 7 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары буенча мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасының компетентлы дәүләт органнары, вазыйфаи затлар белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары эшчәнлегенә тикшерү үткәрергә;

7) ачыкланырга тиешле хәлләргә тикшерү үткәрүдә булышлык күрсәтүне сорап, компетентлы дәүләт органнарына,

Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затларга мөрәҗәгать итәргә;»;

б) 2 пунктның 2 өлешендә «түләүсез» сүзен «түләүсез һәм тоткарлыксыз» сүзләренә алмаштырырга;

4) 13 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары Судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары Судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына» сүзләренә алмаштырырга;

5) 14 статьяның 13 өлешендәге икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гамәлгә куючыларның (уртак гамәлгә куючыларның) берсе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары булган вакытлы матбугат басмасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бәяләмәләрен һәм башка документларын бастырып чыгарудан баш тартырга хокуксыз.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 ноябре
№ 90-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1260. «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Татарстан Республикасы министры вазыйфасы буенча айлык акчалата гомуми хезмәт хакы күләме Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга айлык акчалата гомуми хезмәт хакы күләмнәрен арттыру (индексацияләү) турында карар Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кабул ителә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы 2013 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 15 ноябре
№ 91-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1261. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнарының (алга таба – дәүләт хакимияте органнары) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы (алга таба – Муниципаль берәмлекләр советы) белән үзара эшчәнлеге принципларын һәм Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлек буенча дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен билгели.

2 статья. **Дәүләт хакимияте органнарының Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге принциплары**

Дәүләт хакимияте органнарының Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге түбәндәге принципларга нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

1) законлылык;

2) ихтыярыйлык һәм килешеп эшләү;

3) хезмәттәшлек һәм партнерлык;

4) хәбәрдарлык;

5) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очраклардан тыш, дәүләт хакимияте органнарының Муниципаль берәмлекләр советы эшчәнлегенә катышмавы һәм Муниципаль берәмлекләр советының дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегенә катышмавы.

3 статья. **Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлек буенча дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләре**

1. Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлек буенча дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт хакимияте органнарының җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар проектлары әзерләве турында Муниципаль берәмлекләр советына хәбәр итү;

2) Муниципаль берәмлекләр советы белән килештереп, аның вәкилләрен әлеге Законда каралган очракларда һәм тәртиптә дәүләт хакимияте органнары эшенә җәлеп итү;

3) Муниципаль берәмлекләр советы белән килештереп, дәүләт хакимияте органнары вәкилләренең әлеге Законда, Муниципаль берәмлекләр советы Уставында каралган очракларда һәм тәртиптә аның эшендә катнашуы;

4) уртак консультатив-киңәшү органнары төзү;

5) дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Муниципаль берәмлекләр советына мәгълүмати, оештыру-методик һәм башка ярдәм күрсәтү.

2. Дәүләт хакимияте органнары, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган вәкаләтләрдән тыш, Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлек буенча федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкарырга мөмкин.

4 статья. **Дәүләт хакимияте органнарының җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар проектлары әзерләве турында Муниципаль берәмлекләр советына хәбәр итү**

1. Дәүләт хакимияте органнарының җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар проектлары әзерләве турында Муниципаль берәмлекләр советына хәбәр итү мондый проектларны Муниципаль берәмлекләр советы тарафыннан карауны тәэмин итү, шулай ук күрсәтелгән проектларга Муниципаль берәмлекләр советының бәяләмәләрен әзерләү һәм аларны тиешле дәүләт хакимияте органнарына җибәрү максатларында башкарыла.

2. Дәүләт хакимияте органнарының җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган

норматив хокукый актлар проектлары әзерләве турында Муниципаль берәмлекләр советына хәбәр итү бу проектларны, срогын күрсәтеп, Муниципаль берәмлекләр советына җибәрү юлы белән башкарыла, Муниципаль берәмлекләр советы шушы срок дәвамында тиешле дәүләт хакимияте органы адресына күрсәтелгән проектларга бәяләмәләр җибәрә.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган срокта тиешле дәүләт хакимияте органына кергән Муниципаль берәмлекләр советы бәяләмәсе күрсәтелгән дәүләт хакимияте органы яисә аның эшче органы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

4. Норматив хокукый актлар проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча Муниципаль берәмлекләр советы бәяләмәләре тәкъдим итү характерына ия.

5 статья. **Муниципаль берәмлекләр советы вәкилләренең дәүләт хакимияте органнары эшендә катнашуы**

1. Муниципаль берәмлекләр советы вәкилләре билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы утырышларында, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм аның Президиумы утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Муниципаль берәмлекләр советы вәкилләре, дәүләт хакимияте органнары белән килештереп, түбәндәгеләрдә катнашырга хокуклы:

1) җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар проектларын караганда дәүләт хакимияте органнарында төзелгән комитетлар, комиссияләр, эшче төркемнәр, башка шундый органнар эшендә;

2) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программалары проектлары турында фикер алышуда;

3) аерым муниципаль берәмлек дәрәҗәсендә дә, гомумән Татарстан Республикасы буенча да җирле бюджетлар керемнәренең муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләренә туры килүен бәяләүдә;

4) исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше күләмен, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерийларын билгеләү методикасы турында фикер алышуда;

5) җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган дотацияләр күләме, җирлекләргә регио-

наль финанс ярдәме фонды һәм муниципаль районнарга (шәһәр округларына) региональ финанс ярдәме фонды күләме, шулай ук җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләме турында фикер алышуда;

6) федераль салымнардан һәм җыемнардан һәм (яисә) Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм салымнар һәм җыемнар турында законнар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле региональ салымнардан керемнәрне җирле бюджетларга күчерү нормативлары турында фикер алышуда;

7) Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен ачыклау өчен нормативларны исәпләү алымы (методикасы) турында фикер алышуда;

8) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программаларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ресурслары күләме, мондый ресурсларны булдыру чыганаклары хакында фикер алышуда;

9) муниципаль берәмлекләрне һәм тулаем алганда Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү өстенлекләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган теге яисә бу программаларны гамәлгә ашыруның чиратлылыгы турында фикер алышуда;

10) муниципаль берәмлекләрнең һәм тулаем алганда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен яхшырту буенча дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының уртак чаралар планнары турында фикер алышуда;

11) җирле үзидарәне оештыру мәсьәләләре буенча мәгълүматны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәҗрибәсен җыюда, өйрәнүдә һәм анализлауда.

6 статья. **Дәүләт хакимияте органнары вәкилләренең Муниципаль берәмлекләр советы эшендә катнашуы**

1. Дәүләт хакимияте органнары Муниципаль берәмлекләр советы тәкъдиме белән үзләренең вәкилләрен Муниципаль

берәмлекләр советы һәм (яисә) аның идарә органнары, шулай ук Муниципаль берәмлекләр советында төзелгән комитетлар, комиссияләр, эшче төркемнәр, башка шундый органнар эшендә катнашу өчен җибәрә.

2. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеген тәэмин итүгә вәкаләтле органны һәм (яисә) вазыйфаи затны билгели.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеген тәэмин итүгә вәкаләтле органны һәм (яисә) вазыйфаи затны билгели.

4. Муниципаль берәмлекләр советы Уставында каралган очракларда Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Муниципаль берәмлекләр советына аның идарә органнары составына (иң югары идарә органыннан тыш) кертү (сайлау) өчен кандидатуралар тәкъдим итәргә хокуклы.

7 статья. **Уртак консультатив-киңәшү органнары төзү**

Җирле үзидарәне үстерү эшчәнлеген координацияләү максатларында дәүләт хакимияте органнары һәм Муниципаль берәмлекләр советы уртак консультатив-киңәшү органнары төзергә мөмкин.

8 статья. **Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Муниципаль берәмлекләр советына мәгълүмати, оештыру-методик һәм башка ярдәм күрсәтү**

Дәүләт хакимияте органнары:

1) «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Муниципаль берәмлекләр советының дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итә;

2) Муниципаль берәмлекләр советына дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән, җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актларны җибәрә;

3) Муниципаль берәмлекләр советына методик һәм белешмә материалларны нәшер итүдә ярдәм күрсәтергә мөмкин;

4) Муниципаль берәмлекләр советына җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча семинарлар, конференцияләр, форумнар, башка шундый чаралар үткәрүдә ярдәм күрсәтергә мөмкин;

5) федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән рәвешләрдә Муниципаль берәмлекләр советы эшчәнлегенә үз компетенциясе чикләрендә башка ярдәм күрсәтә.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 15 ноябре
№ 92-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1262. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендә «(кадрлар резервында булуны һәм башка очракларны да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры**

1. Дәүләт органнарында шул органнарның структурасын исәпкә алып булдырыла һәм Федераль закон нигезендә вазыйфалар категорияләре, төркемнәре буенча классификацияләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының тиешле бүлекләре булып торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген тәшкил итә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры Федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының төзелү принципларын исәпкә алып төзелә һәм Татарстан Республикасы Президенты указы белән раслана.»;

3) 10 статьяда:

а) 1 өлештә «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә «профессиональ» сүзен төшереп калдырырга;

в) 5 өлештә:

беренче абзацта «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

г) 6 өлештә «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

4) 14 статьяның 1 өлешендәге 11 пунктында «һөнәрен үзгәртергә, квалификациясен күтәрергә һәм стажировка

үтәргә» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алырга» сүзләренә алмаштырырга;

5) 20 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында «белгечлек» сүзеннән соң «, эзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә;

6) 21 статьяда:

а) 10 өлештә «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 10[1] өлеш өстәргә:

«10[1]. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22[1] статьясы нигезендә иҗтимагый совет оештырылган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органында аттестация комиссиясе составына әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән затлар белән бергә бу иҗтимагый советлар вәкилләре дә кертелә. Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны аттестация комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.»;

в) 15 өлештә:

2 пунктта «билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «квалификация күтәрүне һәм яңадан профессиональ әзерләүне» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алуны» сүзләренә алмаштырырга;

г) 16 өлештә:

1 пунктта «билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «квалификациясен күтәрүгә яисә яңадан профессиональ әзерлек узуга» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алуга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча түбәнрәк төшерелә һәм, кадрлар резервында булган очракта, аннан төшереп калдырылырга тиеш.»;

д) 17 өлештә «яңадан профессиональ әзерләүдән, квалификациясен күтәрүдән» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алудан» сүзләренә алмаштырырга;

7) 28 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

8) 30 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9[1] һәм 9[2] пунктлар өстәргә:

«9[1]) дәүләт хезмәткәрен Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирдә урнашкан дәүләт органына дәүләт хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләгәндә – дәүләт хезмәткәре һәм аның гаиләсе әгъзалары Татарстан Республикасы чикләрендә башка җиргә хезмәт урынына күчеп китүгә бәйле чыгымнарны дәүләт хезмәткәре ротация тәртибендә җибәрелә торган дәүләт органы акчалары исәбеннән; вакытлы хезмәт контрактын өзгәннән соң яисә дәүләт хезмәтендә биләгән вазыйфасыннан азат ителгәннән соң һәм дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң, дәүләт хезмәткәре һәм аның гаилә әгъзалары Татарстан Республикасы чикләрендә башка җиргә күчеп китүгә бәйле чыгымнарны дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәтендә соңгы вазыйфаны биләгән дәүләт органы акчалары исәбеннән түләү. Әлеге пунктта каралган чыгымнарны түләү дәүләт хезмәткәрен башка дәүләт органына күчергәндә дәүләт хезмәткәре һәм аның гаилә әгъзалары Татарстан Республикасы чикләрендә башка җиргә күчеп китүгә бәйле чыгымнарны түләү өчен билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда башкарыла;

9[2]) Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирдә урнашкан дәүләт органына дәүләт хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләнгән дәүләт хезмәткәрен хезмәт торак урыны белән тәэмин итү, ә яңа хезмәт урынында хезмәт торак урыны булмаган очракта – дәүләт хезмәткәренә торак урынын наемга (поднаемга) алу чыгымнарын түләү. Дәүләт хезмәткәре социаль наем шартнамәсе буенча торак урынын элек дәүләт хезмәтендә булган урыны буенча биләп торса, дәүләт хезмәткәре белән төзелгән торак урынына социаль наем шартнамәсе дәүләт хезмәте вазыйфасын ротация тәртибендә биләү турында вакытлы хезмәт контракты гамәлдә булган вакыт дәвамында наемга бирүче таләбе буенча өзелә алмый. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләрен хезмәт торак урыннары белән тәэмин итү тәртибе һәм шартлары, шулай ук торак урынын наемга (поднаемга) алу чыгымнарын түләү тәртибе һәм күләмнәре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә;»;

9) 31 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «яңа һөнәргә өйрәнү, белгечлеген арттыру һәм стажировка үтү» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте вазыйфалары кыскартылганда яисә дәүләт органы бетерелгәндә, Федераль закон нигезендә дәүләт хезмәтенең бүтән вазыйфасын биләү;»;

10) 32 статьяның 3 өлешендә «башкарылучы яңа һөнәргә өйрәнү, белгечлеген арттыру һәм стажировка үтү» сүзләрен «башкарыла торган өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

11) 34 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында «дәүләт хезмәткәрләрен профессиональ әзерләү, аларны яңадан һөнәри әзерләү, квалификацияләрен күтәрү һәм дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше программалары нигезендә стажировка» сүзләрен «дәүләт хезмәте өчен кадрлар әзерләү, шулай ук дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше программалары нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү» сүзләренә алмаштырырга;

12) түбәндәге эчтәлекле 34[1] статья өстәргә:

«34[1] статья. **Дәүләт хезмәткәрләре ротациясе**

1. Дәүләт хезмәткәрләре ротациясе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында, дәүләт хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм коррупциягә каршы тору максатларында, дәүләт хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шул ук яисә башка органында бүтән дәүләт хезмәте вазыйфаларына билгеләү юлы белән үткәрелә. Дәүләт хезмәткәрләре ротациясе Федераль законда каралган тәртиптә үткәрелә.

2. Дәүләт хезмәткәрләре ротациясе карала торган дәүләт хезмәте вазыйфалары исемлеге һәм ротация үткәрү планы Татарстан Республикасы Президенты указы белән йә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Дәүләт хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органына дәүләт хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләү бу органнар җитәкчеләренең килештерелгән карарлары белән башкарыла.»;

13) 35 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35 статья. **Дәүләт хезмәте өчен кадрлар әзерләү»;**

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хезмәте өчен кадрлар әзерләү Россия Федерациясе законнары нигезендә һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем мәгариф оешмаларында башкарыла.»;

в) 2 өлештә «укыту хакындагы шартнамә» сүзләрен «максатчан кабул итү турында шартнамә яисә максатчан укыту турында шартнамә» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

14) 36 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36 статья. **Дәүләт хезмәткәренә өстәмә һөнәри белем бирү»;**

б) 1 өлештә «, квалификациясен күтәрүе һәм стажировка үтүе» сүзләрен «һәм квалификациясен күтәрүе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

г) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт хезмәткәренә өстәмә һөнәри белем бирү аның бөтен дәүләт хезмәтен узу чорында гамәлгә ашырыла.»;

д) 4 өлештә:

беренче абзацта «яңадан һөнәри әзерләүгә, аның квалификациясен күтәрүгә һәм аны стажировкага» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алуга» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) дәүләт хезмәткәрен Федераль закон нигезендә дәүләт хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләп кую.»;

е) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Дәүләт хезмәткәренә өстәмә һөнәри белем бирү өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда башкарыла.»;

ж) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

з) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Дәүләт хезмәткәренә өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф турындагы законнарда каралган теләсә кайсы рәвештә дәүләт хезмәтеннән аерылып яисә аерылмыйча башкарыла.»;

и) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Дәүләт хезмәткәренең өстәмә һөнәри белем алуы квалификация турындагы документ беләп раслана һәм дәүләт хезмәткәрен кадрлар резервына кертү яисә дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте вазыйфасын биләвен дәвам иттерү өчен өстенлекле нигез була.»;

к) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Өстәмә һөнәри белем алучы дәүләт хезмәткәренә эшкә яллаучы вәкиле, мәгариф оешмасы, дәүләт органы яисә бүтән оешма тарафыннан өстәмә һөнәри программаны үзләштерү өчен шартлар тудырыла.»;

15) 37 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37 статья. **Дәүләт хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт заказы»;**

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «хезмәткәрләрен һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкалауга» сүзләрен «хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «һәм стажировкалауга» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 2 өлештә «дәүләт хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүне һәм аларның квалификациясен күтәрүне үткәрүгә лицензиясе һәм дәүләт аккредитациясе булган һөнәри белем мәгариф учреждениеләрендә» сүзләрен «өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлештә «хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, квалификациясен күтәрүгә һәм аларны стажировкалауга» сүзләрен «хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә» сүзләренә алмаштырырга;

16) 38 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38 статья. **Дәүләт хезмәтендә кадрлар резервы**

1. Дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен дәүләт хезмәткәрләреннән (гражданнардан) Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы кадрлар резервы һәм Татарстан Республикасы дәүләт органында кадрлар резервы булдырыла.

2. Татарстан Республикасы кадрлар резервын һәм Татарстан Республикасы дәүләт органында кадрлар резервын булдыру һәм алар белән эшләү тәртибен билгели торган Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә Татарстан Республикасы Президенты указы белән раслана.»;

17) 39 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта «, саклаганда һәм тапшырганда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «белешмәләрне дәүләт хезмәткәреннән алу,» сүзләрен «белешмәләрен» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта «яисә электрон саклагычлардан» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктта «федераль законда» сүзләрен «персональ белешмәләр өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «алуны,» сүзен һәм «һәм тапшыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

18) 41 статьяның 1 өлешендә:

а) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) максатчан кабул итү турында шартнамәләр һәм максатчан укыту турында шартнамәләр төзүне оештыру;»;

б) 13 пунктта «хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүне, аларның квалификациясен күтәрүне һәм стажировкалауны» сүзләрен «хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 15 ноябре
№ 93-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

# 1263. 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

1. 2014 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 142 172 188,0 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 151 787 073,4 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 9 614 885,4 мең сум итеп.

2. 2015 елга һәм 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2015 елга 144 436 531,6 мең сум һәм 2016 елга 151 384 626,5 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2015 елга 153 008 549,2 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 4 100 000,0 мең сум, һәм 2016 елга 163 956 664,0 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 9 500 000,0 мең сум итеп;

3) 2015 елга Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 8 572 017,6 мең сум итеп һәм 2016 елга 12 572 037,5 мең сум итеп.

3. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. 2015 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген 87 420 155,4 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 20 314 248,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2016 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген 74 325 927,8 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 7 282 472,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2017 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген 74 215 498,4 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 7 265 720,0 мең сум күләмендә расларга.

4. Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

2014 елда – 87 448 667,4 мең сум күләмендә;

2015 елда – 87 420 155,4 мең сум күләмендә;

2016 елда – 74 325 927,8 мең сум күләмендә.

5. 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулар программасын әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга күчерелергә тиешле түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәрен Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^{1}$ статьясындагы 2 пункты нигезендә 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасының

бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**6 статья**

1. Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционер җәмгыятьләрнең идарә органнарындагы дәүләт вәкилләре, 2013, 2014 һәм 2015 еллар нәтиҗәләре буенча чиста табышны бүлү һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча акционер җәмгыятьләрнең идарә органнары (директорлар советы, күзәтү советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, акцияләр буенча дивидендларны тиешенчә 2014, 2015 һәм 2016 елларның 1 сентябренә кадәр срокта (әгәр җәмгыять уставында башка срок билгеләнмәгән булса) ел йомгаклары буенча чиста табышның кимендә 30 проценты күләмендә акчалата түләү өчен тавыш бирергә тиеш.

2. 2014 елда, 2015 һәм 2016 еллар план чорында Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының 2013, 2014 һәм 2015 еллар йомгаклары буенча салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган өлеше тиешенчә 2014, 2015 һәм 2016 елларның 1 июленә кадәр чиста табышның 30 проценты күләмендә кертелә дип билгеләргә.

**7 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

**8 статья**

1. 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Законга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Законга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган гомуми күләмен 2014 елга 18 494 289,5 мең сум, 2015 елга 18 948 122,1 мең сум һәм 2016 елга 19 695 202,2 мең сум күләмендә расларга.

**9 статья**

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга һәм физик затларга субсидияләр, шулай ук Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{5}$ статьясында каралган бюджетара трансфертлар әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

**10 статья**

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә 2014 елда, 2015 һәм 2016 еллар план чорында җирлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә 2014 елда, 2015 һәм 2016 еллар план чорында муниципаль районнар (шәһәр округлары) бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 11 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге статьяда күрсәтелгән бюджетара субсидияләр җирле бюджетларда тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан законнар нигезендә карала.

4. 2014 елда, 2015 һәм 2016 еллар план чорында әлеге статьяда каралган җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара субсидияләрне күчерү ай саен тигез өлешләрдә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле субсидия күләмен бер кешегә исәпләгәндә аерым муниципаль берәмлек өчен финанс хисабы елында бер кешегә, җирле бюджетның исәпләнгән салым керемнәре белән (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) бер кешегә исәпләнгән салым керемнәренең икеләтелгән уртача дәрәҗәсе аермасы 2014 елда 5

процент, 2015 елда 15 процент, 2016 елда 45 процент тәшкил итә дип билгеләргә.

**11 статья**

1. 2014 елга җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 13 168,5 мең сум итеп расларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә 4 004,0 мең сум күләмендә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә 9 164,5 мең сум күләмендә бирергә.

2. 2015 елга җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 13 395,5 мең сум итеп расларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә 4 057,3 мең сум күләмендә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә 9 338,2 мең сум күләмендә бирергә.

3. 2016 елга җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 13 609,5 мең сум итеп расларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә 4 110,5 мең сум күләмендә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә 9 499,0 мең сум күләмендә бирергә.

4. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләргә дотацияләр исәплəгәндә һәм муниципаль районнар бюджетларына җирлекләргә финанс ярдәменең региональ фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр исәпләгәндә финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие күрсәткечен 2014 елга бер кешегә 161,9 сум, 2015 елга бер кешегә 163,4 сум, 2016 елга бер кешегә 164,9 сум итеп билгеләргә.

**12 статья**

1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

2014 елга – 8 415 684,9 мең сум күләмендә;

2015 елга – 9 472 067,5 мең сум күләмендә;

2016 елга – 10 846 050,3 мең сум күләмендә.

Әлеге өлештә күрсәтелгән дотацияләрне 2014 елда 8 164 565,7 мең сум, 2015 елда 9 115 175,5 мең сум, 2016 елда 10 191 242,1 мең сум күләмендә физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары белән алмаштырырга.

2. 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне һәм физик затлар керемнәренә салымнан суммаларның шул дотацияләрне алмаштыра торган өстәмә нормативларын әлеге Законга 12 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр исәпләгәндә файдаланыла торган муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет белән тәэмин ителешен исәпләүне тигезләү критерие күрсәткечен 2014 елга 1,757, 2015 елга 1,809, 2016 елга 1,901 итеп билгеләргә.

**13 статья**

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында җирле бюджетларга бирелә торган субсидияләр күләмен 2014 елга 12 180 399,8 мең сум, 2015 елга 10 516 738,1 мең сум һәм 2016 елга 9 374 856,1 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

1) муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә һәм аларның бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүгә муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр, әлеге Законга 13 нче кушымта нигезендә бүлеп;

2) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыруга, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыруга, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап тәрбияләүне, тотуны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр, әлеге Законга 14 нче кушымта нигезендә бүлеп;

3) күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга һәм гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр 2014 елга 3 025 647,3 мең сум, 2015 елга 1 993 352,0 мең сум һәм 2016 елга 1 635 024,5 мең сум күләмендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә бүлеп;

4) Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр 2014 елга 50 000,0 мең сум, 2015 елга 50 000,0 мең сум күләмендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә бүлеп.

**14 статья**

Җирле бюджетларга субвенцияләр күләмен 2014 елга 19 798 789,7 мең сум, 2015 елга 19 822 242,8 мең сум, 2016 елга 19 889 599,9 мең сум итеп расларга, шул исәптән:

1) җирлекләргә региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 15 нче кушымта нигезендә бүлеп;

2) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем алуны тәэмин итүгә хокукларны гамәлгә ашыру буенча дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 16 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

3) муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез белем алуга хокукларны гамәлгә ашыру буенча дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 17 нче кушымта нигезендә бүлеп;

4) мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 18 нче кушымта нигезендә бүлеп;

5) мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүматитехнологик яктан тәэмин итүне тормышка ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр

округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 19 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

6) балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 20 нче кушымта нигезендә бүлеп;

7) административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 21 нче кушымта нигезендә бүлеп;

8) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 22 нче кушымта нигезендә бүлеп;

9) халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр 2014 елга 513,8 мең сум, 2015 елга 539,7 мең сум һәм 2016 елга 567,0 мең сум күләмендә;

10) архив эше өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 23 нче кушымта нигезендә бүлеп;

11) опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 24 нче кушымта нигезендә бүлеп;

12) күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 25 нче кушымта нигезендә бүлеп;

13) гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез файдалануны тәэмин итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр 2014 елга 654 376,2 мең сум, 2015 елга 654 376,2 мең сум һәм 2016 елга 654 376,2 мең сум күләмендә;

14) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 26 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

15) хайваннарның авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулардан яклау чараларын уздыруны оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 27 нче кушымта нигезендә бүлеп;

16) йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яисә таралу өчен шартлар булган һәм сакланып кала торган территорияләрдә һәм урыннарда дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация үткәрү чараларын, лаборатор тикшеренү методларын кулланып уздырыла торган санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны башкаруны оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 28 нче кушымта нигезендә бүлеп;

17) хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 29 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

18) граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 30 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

19) Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчылары урынына кандидатлар исемлеген төзү (үзгәртү, тулыландыру) вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 31 нче кушымта нигезендә бүлеп;

20) Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәпкә алуларын уздыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 32 нче кушымта нигезендә бүлеп.

**15 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен 2014 елга 9 896 017,3 мең сум, 2015 елга 10 145 700,4 мең сум, 2016 елга 10 282 562,6 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар күләмен 2014 елга 7 755 061,2 мең сум, 2015 елга 7 802 437,2 мең сум, 2016 елга 7 925 188,9 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

1) мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруны өстәмә рәвештә финанс белән тәэмин итүгә 2014 елга 2 259 244,6 мең сум, 2015 елга 2 200 641,5 мең сум, 2016 елга 2 208 605,3 мең сум күләмендә;

2) медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә 2014 елга 178 383,0 мең сум, 2015 елга 179 106,7 мең сум, 2016 елга 179 867,6 мең сум күләмендә.

3. Әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар 2014 елда, 2015 һәм 2016 еллар план чорында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына ай саен күчерелә дип билгеләргә.

**16 статья**

Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2014 елга 11 750 000,0 мең сум, 2015 елга 13 020 000,0 мең сум, 2016 елга 14 380 000,0 мең сум күләмендә расларга һәм аларны тиешенчә 2014, 2015 һәм 2016 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы гамәлләрен тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**17 статья**

2014 елда инвестиция салым кредитларын бирүгә юнәлдерелә торган чараларның иң чик күләмен 100 000,0 мең сум итеп билгеләргә.

**18 статья**

1. Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан элегрәк бирелгән бюджет кредитларын рефинанслау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләргә бюджет кредитлары финанс елы чикләрендә 2014 елда 39 200,0 мең сумга кадәр, 2015 елда 7 300,0 мең сумга кадәр бирелә дип билгеләргә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән кредиттан файдаланган өчен түләүне бюджет кредиты бирү турындагы шартнамәне төзү көненә Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдә булган рефинанслау ставкасының өчтән икесе күләмендә билгеләргә.

3. Бюджет кредитлары муниципаль берәмлекләргә бюджет кредитларын кире кайтару, тиешле шартнамәләрдә каралган процентларны һәм бүтән түләүләрне башкару буенча үз йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итмичә генә бирелә.

4. Элек бирелгән кредитлар буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләнми калган бурычы булган муниципаль берәмлеккә бюджет кредиты бюджет кредитын каплауның нигезләнгән чыганаклары булмаган очракта һәм бюджет законнары таләпләре үтәлмәгәндә бирелә алмый.

5. Бюджет кредиты әлеге Законда каралган бюджет ассигнованиеләре шартларында һәм чикләрендә, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелгән шартнамәгә таянып, Россия Федерациясе Бюджет кодексының һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларының нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә бирелә.

**19 статья**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары 2014 елда, 2015 һәм 2016 еллар план чорында Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең һәм дәүләт учреждениеләрендә эшләүчеләрнең санын арттыруга китерерлек карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирле үзидарә органнарына 2014 елда, 2015 һәм 2016 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләрдә эшләүчеләрнең санын арттыруга китерерлек карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**20 статья**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2014 елда, 2015 һәм 2016 еллар план чорында элек бирелгән бюджет кредитлары буенча бурычны биш елга кадәр срокка реструктуризацияләү турында карарлар кабул итәргә хокуклы.

2. Максатка яраксыз файдаланылган чаралар суммалары, шулай ук кредитлар, суд карары нигезендә эзләтеп алынырга тиешле исәпләнелгән процентлар һәм пенялар буенча бурыч суммалары реструктуризацияләнергә тиеш түгел.

3. Реструктуризацияләү Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелгән килешү нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларының нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**21 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында түбәндәгеләрдән алына торган бюджетара трансфертларны һәм кире кайтарылмый торган акчаларны әлеге Законга 33 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга:

федераль бюджеттан 2014 елда 12 927 679,3 мең сум, 2015 елда 8 953 435,7 мең сум һәм 2016 елда 8 718 440,1 мең сум күләмендә;

дәүләт корпорациясеннән – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фондыннан 2014 елда 1 652 516,3 мең сум, 2015 елда 620 221,0 мең сум һәм 2016 елда 261 893,5 мең сум күләмендә.

**22 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**23 статья**

Товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактларына түләүгә файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләреннән артмаган сумма күләмендә 2013 елда әлеге дәүләт контрактларын түләү шартлары нигезендә әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә түләнергә тиешле Татарстан Республикасы бюджетының 2014 елның 1 гыйнварына калган акчалары 2014 елда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**24 статья**

Суд эшчәнлеге турындагы, башкару эшчәнлеге турындагы һәм бөлгенлек (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^2$ статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына таянып, Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләре буенча бурычлыларның бурычын җайга салу шартларын билгели торган, йөкләмәләр үтәүне кичектереп тору, йөкләмәләрне өлешләп үтәү турында, шулай ук бурычлыларны исәпләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итү юлы белән йөкләмәләре күләмен киметү турында килешү шартнамәләре төзергә хокуклы.

**25 статья**

2014 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр чорга түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясындагы дүртенче өлешенең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3);

2) «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш)

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән дәүләт ярдәмен финанслау өлешендә;

3) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 12 өлешенең (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3);

4) Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $55^3$ статьясындагы 2 һәм 3 пунктларының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7; Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь);

5) «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясындагы 1 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11; 2007, № 11; 2008, № 6) Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән финанслау өлешендә;

6) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы өченче абзацының, 5 статьясындагы 4 өлешенең, 2 нче кушымтасының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 7 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь);

7) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статья-

сындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3; Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әлмәт муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелүдән тыш;

8) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь), Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелүдән тыш.

**26 статья**

Әлеге Закон 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 25 ноябре
№ 94-ТРЗ

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

1 нче таблица

# 2014 елга
# Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 9 614 885,4 |
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджет чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 9 568 637,0 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетлар чараларының калган өлешләрен арттыру | -162 600 396,4 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен арттыру | -162 600 396,4 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | -162 600 396,4 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | -162 600 396,4 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетлар чараларының калган өлешләрен киметү | 172 169 033,4 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен киметү | 172 169 033,4 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 172 169 033,4 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 172 169 033,4 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 46 248,4 |
| 01 06 01 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләр һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләре | 7 000,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 01 06 01 00 00 0000 630 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 7 000,0 |
| 01 06 01 00 02 0000 630 | Татарстан Республикасы милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 7 000,0 |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -20 342 760,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0 |
| 01 06 04 01 02 0000 810 | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, дәүләт гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -7 342 760,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 01 06 04 02 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -7 342 760,0 |
| 01 06 04 02 02 0000 820 | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -7 342 760,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 39 248,4 |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 78 448,4 |
| 01 06 05 01 00 0000 600 | Юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 9 248,4 |
| 01 06 05 01 02 0000 640 | Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 9 248,4 |
| 01 06 05 02 00 0000 600 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 69 200,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 01 06 05 02 02 0000 640 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 69 200,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 500 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -39 200,0 |
| 01 06 05 02 00 0000 500 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -39 200,0 |
| 01 06 05 02 02 0000 540 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -39 200,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 20 342 760,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 20 342 760,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Татарстан Республикасы бюджеты тарафыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 20 342 760,0 |
| Барлык чыганаклар | | 9 614 885,4 |

2 нче таблица

# 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2015 ел | 2016 ел |
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 8 572 017,6 | 12 572 037,5 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | -62 451,6 | -93 677,4 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | -62 451,6 | -93 677,4 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын түләү | -62 451,6 | -93 677,4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларын Татарстан Республикасы бюджетыннан түләү | -62 451,6 | -93 677,4 |
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 8 627 139,4 | 12 665 714,9 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетлар чараларының калган өлешләрен арттыру | -164 765 409,4 | - 158 667 098,5 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен арттыру | -164 765 409,4 | - 158 667 098,5 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | -164 765 409,4 | - 158 667 098,5 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | -164 765 409,4 | - 158 667 098,5 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетлар чараларының калган өлешләрен киметү | 173 392 548,8 | 171 332 813,4 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен киметү | 173 392 548,8 | 171 332 813,4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 173 392 548,8 | 171 332 813,4 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 173 392 548,8 | 171 332 813,4 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 7 329,8 | |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -20 314 248,0 | -7 282 472,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0 | |
| 01 06 04 01 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 06 04 01 02 0000 810 | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0 | |
| 01 06 04 02 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -7 314 248,0 | -7 282 472,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -7 314 248,0 | -7 282 472,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 06 04 02 02 0000 820 | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -7 314 248,0 | -7 282 472,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 7 329,8 | |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 14 629,8 | |
| 01 06 05 01 00 0000 600 | Юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 7 329,8 | |
| 01 06 05 01 02 0000 640 | Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 7 329,8 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 06 05 02 00 0000 600 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 7 300,0 | |
| 01 06 05 02 02 0000 640 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 7 300,0 | |
| 01 06 05 00 00 0000 500 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -7 300,0 | |
| 01 06 05 02 00 0000 500 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -7 300,0 | |
| 01 06 05 02 02 0000 540 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -7 300,0 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 20 314 248,0 | 7 282 472,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 20 314 248,0 | 7 282 472,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Татарстан Республикасы бюджеты тарафыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 20 314 248,0 | 7 282 472,0 |
| Барлык чыганаклар | | 8 572 017,6 | 12 572 037,5 |

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

# 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт үзара хисаплашулары программасы

(мең сумнарда)

| | Суммасы | |
|---|---|---|
| | 2015 ел | 2016 ел |
| Эчке дәүләт үзара хисаплашулары | | |
| жәлеп итү | 0,0 | 0,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга юнәлдерелә торган акчалар күләме | 62 451,6 | 93 677,4 |

| | | |
|---|---|---|
| шул исәптән:<br>бюджет кредитлары | | |
| җәлеп итү | 0,0 | 0,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга юнәлдерелә торган акчалар күләме | 62 451,6 | 93 677,4 |

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

1 нче таблица

## 2014 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре

(мең сумнарда)

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Салым һәм салым булмаган керемнәр | 1 00 00000 00 0000 000 | 127 493 729,3 |
| Табышка салымнар, керемнәр | 1 01 00000 00 0000 000 | 83 101 306,6 |
| Оешмалар табышына салым | 1 01 01000 00 0000 110 | 45 000 000,0 |
| Физик затлар керемнәренә салым | 1 01 02000 01 0000 110 | 38 101 306,6 |
| Россия Федерациясе территориясендә реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) салымнар | 1 03 00000 00 0000 000 | 15 539 197,0 |
| Россия Федерация-се территориясендә җитештерелә торган акцизлы товарларга (продукциягә) акцизлар | 1 03 02000 01 0000 110 | 15 539 197,0 |
| Җыелма керемгә салымнар | 1 05 00000 00 0000 000 | 3 250 103,7 |
| Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 01000 00 0000 110 | 3 250 103,7 |

| | | |
|---|---|---|
| Мөлкәткә салымнар | 1 06 00000 00 0000 000 | 21 705 124,0 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым | 1 06 02000 02 0000 110 | 18 500 000,0 |
| Транспорт салымы | 1 06 04000 02 0000 110 | 3 200 000,0 |
| Уен бизнесына салым | 1 06 05000 02 0000 110 | 5 124,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен салымнар, җыемнар һәм даими түләүләр | 1 07 00000 00 0000 000 | 43 000,0 |
| Файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1 07 01000 01 0000 110 | 43 000,0 |
| Дәүләт пошлинасы | 1 08 00000 00 0000 000 | 255 000,0 |
| Дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук юридик әһәмиятле бүтән гамәлләрне башкарган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 07000 01 0000 110 | 255 000,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 1 11 00000 00 0000 000 | 495 030,0 |
| Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләренә туры килә торган табыш яисә Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының яисә муниципаль берәмлекләрнең акцияләре буенча дивидендлар рәвешендәге керемнәр | 1 11 01000 00 0000 120 | 215 296,0 |
| Ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар | 1 11 03000 00 0000 120 | 127 574,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) түләүле файдалануга тапшырган өчен аренда түләве йә башка түләү рәвешендә алына торган керемнәр | 1 11 05000 00 0000 120 | 48 965,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән түләүләр | 1 11 07000 00 0000 120 | 60 495,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган чаралар | 1 11 08000 00 0000 120 | 42 700,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 00000 00 0000 000 | 326 348,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 12 01000 01 0000 120 | 307 600,0 |
| Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 02000 00 0000 120 | 14 321,0 |
| Урманнардан файдаланган өчен түләү | 1 12 04000 00 0000 120 | 4 427,0 |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 00000 00 0000 000 | 214 940,0 |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) керемнәр | 1 13 01000 00 0000 130 | 110 184,2 |
| Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 02000 00 0000 130 | 104 755,8 |
| Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 1 14 00000 00 0000 000 | 35 000,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр | 1 14 02000 00 0000 000 | 35 000,0 |
| Административ түләүләр һәм җыемнар | 1 15 00000 00 0000 000 | 1 206,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Билгеләнгән функцияләр башкарган өчен дәүләт һәм муниципаль органнар (оешмалар) тарафыннан алына торган түләүләр | 1 15 02000 00 0000 140 | 1 206,0 |
| Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 1 16 00000 00 0000 000 | 1 775 974,0 |
| Товар базарларында конкуренция, финанс хезмәтләре күрсәтү базарында конкуренцияне яклау өлкәсендә монополиягә каршы законнарны, табигый монополияләр турындагы законнарны һәм бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 02000 00 0000 140 | 2 200,0 |
| Реклама турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 26000 01 0000 140 | 4 253,0 |
| Янгын куркынычсызлыгы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 27000 01 0000 140 | 20 000,0 |
| Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә хокук бозулар өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 30000 01 0000 140 | 1 743 000,0 |
| Товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 33000 00 000 140 | 2 445,0 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан бүтән кертемнәр | 1 16 90000 00 0000 140 | 4 076,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 00000 00 0000 000 | 751 500,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 05000 00 0000 180 | 751 500,0 |
| Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 00 00000 00 0000 000 | 14 678 458,7 |

| | | |
|---|---|---|
| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 02 00000 00 0000 000 | 13 025 942,4 |
| Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларына дотацияләр | 2 02 01000 00 0000 151 | 2 324 243,4 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субсидияләр (бюджетара субсидияләр) | 2 02 02000 00 0000 151 | 381 738,8 |
| Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең бюджетларына субвенцияләр | 2 02 03000 00 0000 151 | 8 911 170,8 |
| Башка бюджетара трансфертлар | 2 02 04000 00 0000 151 | 1 408 789,4 |
| Дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 03 00000 00 0000 000 | 1 652 516,3 |
| Барлык керемнәр | | 142 172 188,0 |

2 нче таблица

## 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре

(мең сумнарда)

| Исеме | Керем коды | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2015 ел | 2016 ел |
| Салым һәм салым булмаган керемнәр | 1 00 00000 00 0000 000 | 134 552 018,6 | 141 726 256,3 |
| Табышка салымнар, керемнәр | 1 01 00000 00 0000 000 | 87 537 485,7 | 92 559 130,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Оешмалар табышына салым | 1 01 01000 00 0000 110 | 45 000 000,0 | 45 000 000,0 |
| Физик затлар керемнәренә салым | 1 01 02000 01 0000 110 | 42 537 485,7 | 47 559 130,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) салымнар | 1 03 00000 00 0000 000 | 17 748 986,0 | 19 600 243,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган акцизлы товарларга (продукциягә) акцизлар | 1 03 02000 01 0000 110 | 17 748 986,0 | 19 600 243,0 |
| Җыелма керемгә салымнар | 1 05 00000 00 0000 000 | 3 392 608,9 | 3 542 239,3 |
| Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 01000 00 0000 110 | 3 392 608,9 | 3 542 239,3 |
| Мөлкәткә салымнар | 1 06 00000 00 0000 000 | 21 805 124,0 | 21 905 124,0 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым | 1 06 02000 02 0000 110 | 18 500 000,0 | 18 500 000,0 |
| Транспорт салымы | 1 06 04000 02 0000 110 | 3 300 000,0 | 3 400 000,0 |
| Уен бизнесына салым | 1 06 05000 02 0000 110 | 5 124,0 | 5 124,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен салымнар, җыемнар һәм даими түләүләр | 1 07 00000 00 0000 000 | 50 200,0 | 50 200,0 |
| Файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1 07 01000 01 0000 110 | 50 200,0 | 50 200,0 |
| Дәүләт пошлинасы | 1 08 00000 00 0000 000 | 269 460,0 | 270 510,0 |
| Дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук юридик әһәмиятле бүтән гамәлләрне башкарган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 07000 01 0000 110 | 269 460,0 | 270 510,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 1 11 00000 00 0000 000 | 535 627,0 | 579 870,0 |
| Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләренә туры килә торган табыш яисә Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының яисә муниципаль берәмлекләрнең акцияләре буенча дивидендлар рәвешендәге керемнәр | 1 11 01000 00 0000 120 | 246 083,0 | 280 838,0 |
| Ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар | 1 11 03000 00 0000 120 | 126 752,0 | 126 750,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) түләүле файдалануга тапшырган өчен аренда түләве йә башка түләү рәвешендә алына торган керемнәр | 1 11 05000 00 0000 120 | 53 587,0 | 53 587,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән түләүләр | 1 11 07000 00 0000 120 | 66 205,0 | 74 195,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган чаралар | 1 11 08000 00 0000 120 | 43 000,0 | 44 500,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 00000 00 0000 000 | 326 581,0 | 326 814,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 12 01000 01 0000 120 | 307 600,0 | 307 600,0 |
| Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 02000 00 0000 120 | 14 321,0 | 14 321,0 |
| Урманнардан файдаланган өчен түләү | 1 12 04000 00 0000 120 | 4 660,0 | 4 893,0 |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 00000 00 0000 000 | 318 138,0 | 329 064,0 |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) керемнәр | 1 13 01000 00 0000 130 | 111 566,3 | 112 712,6 |
| Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 02000 00 0000 130 | 206 571,7 | 216 351,4 |
| Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 1 14 00000 00 0000 000 | 31 000,0 | 26 000,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр | 1 14 02000 00 0000 000 | 30 000,0 | 25 000,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен (бюджет һәм автоном учреждениеләр җир кишәрлекләреннән тыш) сатудан керемнәр | 1 14 06000 00 0000 430 | 1 000,0 | 1 000,0 |
| Административ түләүләр һәм җыемнар | 1 15 00000 00 0000 000 | 603,0 | 402,0 |
| Билгеләнгән функцияләр башкарган өчен дәүләт һәм муниципаль органнар (оешмалар) тарафыннан алына торган түләүләр | 1 15 02000 00 0000 140 | 603,0 | 402,0 |
| Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 1 16 00000 00 0000 000 | 1 784 424,0 | 1 785 160,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Товар базарларында конкуренция, финанс хезмәтләре күрсәтү базарында конкуренцияне яклау өлкәсендә монополиягә каршы законнарны, табигый монополияләр турындагы законнарны һәм бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 02000 00 0000 140 | 2 200,0 | 2 200,0 |
| Реклама турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 26000 01 0000 140 | 4 679,0 | 5 146,0 |
| Янгын куркынычсызлыгы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 27000 01 0000 140 | 20 000,0 | 20 000,0 |
| Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә хокук бозулар өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 30000 01 0000 140 | 1 750 000,0 | 1 750 000,0 |
| Товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 33000 00 0000 140 | 2 690,0 | 2 959,0 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан бүтән кертемнәр | 1 16 90000 00 0000 140 | 4 855,0 | 4 855,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 00000 00 0000 000 | 751 781,0 | 751 500,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 05000 00 0000 180 | 751 781,0 | 751 500,0 |
| Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 00 00000 00 0000 000 | 9 884 513,0 | 9 658 370,2 |
| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 02 00000 00 0000 000 | 9 264 292,0 | 9 396 476,7 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субсидияләр (бюджетара субсидияләр) | 2 02 02000 00 0000 151 | 423 174,2 | 765 543,6 |
| Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларына субвенцияләр | 2 02 03000 00 0000 151 | 7 425 945,1 | 7 615 760,4 |
| Башка бюджетара трансфертлар | 2 02 04000 00 0000 151 | 1 415 172,7 | 1 015 172,7 |
| Дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 03 00000 00 0000 000 | 620 221,0 | 261 893,5 |
| Барлык керемнәр | | 144 436 531,6 | 151 384 626,5 |

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

1 нче таблица

# 2014 елга Россия Федерациясе территориясендә житештерелә торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан жирле бюджетларга күчерелә торган түләүләрнең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә жирле бюджетларга күчерелергә тиешле дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәре

(процентларда)

| Муниципаль район (шәһәр округы) исеме | Түләү нормативлары |
|---|---|
| Әгерже муниципаль районы | 2,1206 |
| Азнакай муниципаль районы | 2,3307 |
| Аксубай муниципаль районы | 2,2427 |
| Актаныш муниципаль районы | 2,8470 |
| Алексеевск муниципаль районы | 1,2535 |
| Әлки муниципаль районы | 2,3980 |
| Әлмәт муниципаль районы | 3,7451 |
| Апас муниципаль районы | 1,6517 |
| Арча муниципаль районы | 3,1520 |
| Әтнә муниципаль районы | 0,7359 |
| Баулы муниципаль районы | 1,2932 |
| Балтач муниципаль районы | 1,5184 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 2,1120 |
| Буа муниципаль районы | 2,0999 |
| Югары Ослан муниципаль районы | 2,9371 |
| Биектау муниципаль районы | 2,7957 |
| Чүпрәле муниципаль районы | 1,3998 |

| | |
|---|---|
| Алабуга муниципаль районы | 2,5903 |
| Зәй муниципаль районы | 2,2358 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 4,8502 |
| Кайбыч муниципаль районы | 1,1910 |
| Кама Тамагы муниципаль районы | 1,5508 |
| Кукмара муниципаль районы | 2,4553 |
| Лаеш муниципаль районы | 2,0684 |
| Лениногорск муниципаль районы | 2,2815 |
| Мамадыш муниципаль районы | 2,7124 |
| Менделеевск муниципаль районы | 0,8256 |
| Минзәлә муниципаль районы | 2,1965 |
| Мөслим муниципаль районы | 0,9619 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 4,5988 |
| Яңа Чишмә муниципаль районы | 0,4840 |
| Нурлат муниципаль районы | 2,6356 |
| Питрәч муниципаль районы | 2,2849 |
| Балык Бистәсе муниципаль районы | 1,7013 |
| Саба муниципаль районы | 1,3605 |
| Сарман муниципаль районы | 1,7147 |
| Спас муниципаль районы | 1,2048 |
| Тәтеш муниципаль районы | 1,2419 |
| Тукай муниципаль районы | 1,8501 |
| Теләче муниципаль районы | 1,6245 |
| Чирмешән муниципаль районы | 1,6297 |
| Чистай муниципаль районы | 1,9523 |
| Ютазы муниципаль районы | 0,8636 |
| Чаллы шәһәре | 4,3330 |
| Казан шәһәре | 7,9673 |
| Барлыгы | 100,0000 |

2 нче таблица

# 2015 һәм 2016 еллар план чорына Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга күчерелә торган түләүләрнең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә җирле бюджетларга күчерелергә тиешле дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәре

(процентларда)

| Муниципаль район (шәһәр округы) исеме | Түләү нормативлары | |
|---|---|---|
| | 2015 ел | 2016 ел |
| Әгерҗе муниципаль районы | 2,1206 | 2,1206 |
| Азнакай муниципаль районы | 2,3307 | 2,3307 |
